ГЛАВА МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.48, с. Майдан, 422587

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 48 нче йорт, Мәйдан авылы, 422587

Тел.: (84379) 35-0-48, факс: (84379) 35-0-48.

13.04.2024 № 1

Карар

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге Мәйдан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Мәйдан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:- Мәйдан авылы торак пункты чикләрендә Яшьләр ур., Кооператив ур., Киров ур. гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» дигән сорау буенча 2024 елның 13 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 86 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 53 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 52 катнашучысы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенның 1 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1 Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авылы җирлеге Мәйдан авылына гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2 Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Мәйдан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Мәйдан авылында 2024 елда

1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?”- Мәйдан авылы торак пункты чикләрендә Яшьләр ур., Кооператив ур., Киров ур. гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» дигән сорау буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегендәге Мәйдан авыл гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Мәйдан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В. В. Михеев